11 ЯШЬЛЕК КИНӘШЧЕ

Альберт Габделфәртов экологияне популярлаштырырга тели

> 2

УШЛА ХӘЛЛӘРЕ

Балтачның унбер хуҗалыклы авылыннан репортаж

> 3

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Иң яхшы пистолет ул – мәхәббәт

> 3

ИСӘНМЕСЕЗ! ШУМБРАТАДА!

«Ватаным Татарстан» – мордва авылында

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 103 (28876) | Чәршәмбе | 20 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

chelnyzags.ru

ИСЕМЕНДӘ – ҖИСЕМЕ

Чаллы

Элек-электән «яшьләр каласы» дип дан алган Чаллы әле дә бирешергә җыенмый: яшь парлар гаилә кора, дөньяга сабыйлар туа тора. Гаилә кыйммәтләрен саклап килүче әнә шундый матур традицияләрне бәйрәм рәвешендә тар кысада гына түгел, ЗАГСта (гражданлык хәле актларын теркәү идарәсен барыбыз да гади генә шулай дияргә күнеккәнбез) тантаналы итеп уздыру күптәннән гадәткә кергән. Ә менә нарасыйларга исем кушу йоласының шундый залда яңгыраш алуына үземнең тәүге тапкыр шаһит булуым.

Бу чара үзе затлы, үзе зәвыклы, үзе… тәмле булып истә калыр, мөгаен. Ни өчен тәмле дисәгез, әти-әнисе кочагында могҗизалы халәттә изрәгән игезәк сабыйларга карап, шуннан да матур сүзне табып булмас. Шулай дигәч, «Бала туу – үзе дә бер могҗиза бит ул, – дип балкып елмайды ЗАГС бүлеге җитәкчесе Равилә Гыйльметдин кызы Зарипова. – Аңа исем кушу чарасы да аеруча үзгә җылылык белән үтә, әле генә туган сабыйларның тәүге бәйрәме булып, анда үзләре дә катнашканга микән…»

Бәйрәм тантанасы Кама балалар медицинасы үзәге бала тудыру бүлеге фотографы Диләрә Эстринаның «Туу тарихы» дип исемләнгән шәхси күргәзмәсе белән танышудан башланды. Диләрә «Милли проектлар: Татарстан – 2021» фотоконкурсында «Турыдан-туры караш» номинациясендә җиңүче булган. Әлеге бәйге өченче ел рәттән «Бердәм Россия» партиясе ярдәмендә, Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова булышлыгында уздырыла. Бала туга багышланган күчмә фотокүргәзмә оештыру идеясе дә аныкы. Чарада ул үзе дә катнашып, әлеге күргәзмәне якын арада Дәүләт Думасы бинасында оештыру тәкъдимен җиткерде.

– Анда әлегергә теләүчеләр күп, тик без урын табарбыз. Яңа форматта тормышка ашырылган әлеге милли проект илдәге демографик проблеманы чишүгә яңа юнәлеш бирер дип ышанам. Күргәзмәдән тыш, демография темасына «түгәрәк өстәл» дә уздырырга мөмкин, – диде ул, туучылар саны кимегәннән-кими барган бу чорда мондый фотосурәтләрнең уңай йогынтысын ассызыклап.

Хикмәт шунда: Диләрә төшергән фотоларда – бала көткән хатын-кызның бәхеттән балкыган карашы, тудыру процессында үзе дә катнашып, сабыен тәүге тапкыр кулына алган әти кешенең сөенечле-мәҗүси йөзе, әле генә дөньяга килгән нарасыйның якты көнгә шаккатып баккан гөнаһсыз күзләре…

– Мондый күргәзмәне без хатын-кызлар консультацияләрендә дә оештырабыз. Йөклелекне өзәргә дип килгән хатын-кыз, бу сурәтләрне күреп, үз уеннан кире кайтырга да мөмкин бит, – ди Диләрә, үзәктә эшләгәндә төрле вакыйгаларга тап булуын искәртеп. – Фотоларның нәкъ менә ЗАГС бинасында урын алуы да тикмәгә түгел. Өйләнешкән парларда, мондагы бәхетле йөзләрне күреп, бәби алып кайту теләге тусын иде.

Бу көнне куанычларын уртаклашырга килгән Снежана һәм Михаил Сергеевлар кулында да, Наталья һәм Айдар Шәйдуллиннар кочагында да – икешәр сабый! Сергеевларда ике кызчык булса, Шәйдуллиннарга 13 июнь көнне кыз да, малай да эләккән, андый игезәкләрне тегеләй-болай гына түгел, «королевские» дип атыйлар!

– Кызга – Амелия, малайга Алмаз дип куштык, – ди Наталья, бу исемнәрне яңгыраш буенча күңелләренә хуш килгәнгә сайлауларын әйтеп. – Мәгънәсен соңрак белдек, Амелия – «эш сөючән, тырыш» дигәнне аңлатса, Алмаз – «кыйммәтле» мәгънәсенә ия икән. Малаем – миңа, кызым әтисенә охшаган.

– Кыз тынычрак, малай көйсезрәк, – дип сүзгә кушыла Айдар, беләгендә месмес килеп яткан нәниен сак кына тибрәтеп. – Балаларны күбрәк саф һавада йөртергә тырышабыз. Үзебезгә генә авыррак инде, ярый әле әби-бабайлары булыша…

Айдар да, Наталья да тумышлары белән Чаллыдан, узган ел өйләнешеп, Казанда яшәгән җирләреннән кабат бирегә кайтканнар. «Беренче УЗИ үткәндә үк карынымда игезәкләр булуын әйттеләр. Шуннан җыендык та Чаллыга – әти-әниләр янына кайттык. Үзебезгә генә авыр булыр дип уйладык», – ди Наталья. Нәселләрендә икешәр дә, өчәр дә игезәк алып кайтучылар барлыгын, алар тарткан йөкнең авырлыгын алдан белгәч, ни хәл итәсең… Яшь әни – һөнәре буенча сатучы-консультант, Айдар КамАЗда двигательләр заводында эшли.

Ахыры 2 нче биттә >

Барысы да көйле

Бүген Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек тармагында кадрларга бәйле кыенлыклар юк. Барлык предприятиеләр – зурлары да, кечкенәләре дә тотрыклы эшли. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков шулай дип белдерде. Агросәнәгать комплексы тармагында 71 меңләп кеше хезмәт куя: 44 меңе – турыдан-туры авыл хуҗалыгында, 27 меңе – азык-төлек җитештерү өлкәсендә.

Министрның беренче урынбасары фикеренчә, тармакка ярдәм итү буенча дәүләт программалары агросәнәгать комплексына һәм эшкәртү сәнәгатенә көйле генә эшләргә булыша. «Ташламалы кредитлар предприятиеләргә эшләү һәм үсү мөмкинлеге бирә. Быел Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы Татарстан компанияләреннән ташламалы кредитларга 318 гаризаны (барлыгы 21 миллиард сумнан артыграк) хуплады инде. Ташламалы инвестицион кредитларга килгәндә, җәмгысы 2,5 миллиард сумга 23 гариза хуплау тапты», – ди Залаков.

Ташламалы карта

Дума депутатлары авыррак тормышлы кешеләр өчен товарларны, дарулар һәм хезмәтләрне ташламалы бәядән сатып алу мөмкинлеге бирердәй социаль дисконт карта кертергә ниятли. Моның өчен «Дәүләт социаль ярдәме турында» законга үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

RT хәбәренә караганда, социаль картаны җан башына туры килә торган кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган аз керемле гаиләләргә һәм ялгыз яшәүчеләргә, тормышта авыр хәлдә калган кешеләргә, инвалидларга, инвалид бала тәрбияләүче ата-аналарга, 55 яшькә җиткән хатын-кызларга һәм 60 яшькә җиткән ир-атларга бирү тәкъдим ителә. Картадан файдалануның билгеле бер вакыт аралыгы белән чикләнмәячәге, ягъни сроксыз булачагы, бөтен Россия территориясендә йөреячәге, аңа хокуклы кешенең гаризасы нигезендә биреләчәге көтелә.

40 йөзеккә кызыккан

Казанда бер сәүдә үзәгенең зәркән кибетеннән 2,8 миллион сумлык бриллиант кашлы йөзекләр урларга маташкан 23 яшьлек егетне тоткарлаганнар. Эчке эшләр министрлыгы идарәсе матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, егет, бер сатучының урынында булмавын абайлап, киштәдән бриллиант кашлы йөзекләр урнаштырылган такталарны җыя башлаган. Икенче сатучы, моны күреп, ярдәмгә чакырган. Шулчак егет ювелир әйберләрен кочагына кыстырып качмакчы булган, әмма йөгергәндә, йөзекле такталар кулыннан шуып, юлда төшеп калган. Ул барлыгы 2,8 миллион сумнан артыграк бәядәге 40 йөзекне урламакчы булган. Угрыны патруль-пост хезмәткәрләре тоткарлап, полиция бүлегенә китергән. «Аеруча зур күләмдә урларга маташу» статьясы буенча җинаять эше кузгатылган.

Яңалык

Яңадан исәпләнә

Ел саен 1 августта эшләүче пенсионерларның пенсиясе яңадан исәпләнә. Быел бу үзгәрешләр эшләмәүчеләргә каралган түләүләргә дә кагылачак. Бу хакта, Россия Пенсия фонды мәгълүматларына таянып, «Известия» хәбәр итә. Моның өчен гариза тапшырырга кирәкми – ул «автомат» рәвештә хәл ителәчәк.

Пенсиягә өстәмә кемнәргә тәтеячәк соң? Эш бирүчеләре тиешле взнослар түләп килгән эшләүче пенсионерларга (аларга өстәмә баллар бирелә), иң күп дигәндә, 314,07 сум өстәмә күздә тотыла. Ягъни пенсиягә өстәмә өч пенсия баллыннан да (быелның гыйнварыннан бер балл бәясе 104,69 сумны тәшкил итә) күбрәк булмаячак.

Эшләмәүче пенсионерларга килгәндә, белгечләр аңлатуынча, хезмәт эшчәнлеген узган елда тәмамлаучы-

Илдар Мөхәммәтҗанов

ларга пенсия артачак, ә алданрак тәмамлаучыларга – юк. Өстәмә күләме алда әйтелгән балларга һәм пенсиягә чыгу срогына бәйле булачак. Монда да күп дигәндә өч пенсия баллы гына өстәләчәк.

Шул ук вакытта 80 яшьтән узганнарның һәм I группа инвалидларның да пенсиясе артачак. Нәтиҗәдә, социаль һәм дәүләт пенсиясен алучылардан тыш (алар өчен билгеләнгән түләүләр гамәлдә), Россиядә яшәүче 7,3 млн пенсионер өстәмә түләү алачак.

Моннан тыш, хәрбиләрнең пенсиясе дә индексацияләнә. Белгечләр аңлатуынча, эчке эшләр органнарының элеккеге хезмәткәрләренең пенсиясе – 1 октябрьгә кадәр, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларның гаилә әгъзаларының, отставкадагы хәрбиләрнең пенсиясе 1 октябрьдән соң артачак.

Россия Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, якындагы өч елда иминиятләштерү пенсияләрен түбәндәгечә арттыру күздә тотыла:

- 2023 елның 1 гыйнварыннан – 6,8 процентка (нәтиҗәдә эшләмәүче пенсионерларның уртача пенсиясе 22174 сумга җитәчәк);
- 2024 елның 1 гыйнварыннан – 6,1 процентка (уртача пенсия 23390 сумны тәшкил итәчәк);
- 2025 елның 1 февраленнән – 4 процентка һәм 2025 елның 1 апреленнән – 3,6 процентка (24477 сум булачак).

Сүзгә-сүз

Анатолий АРТАМОНОВ, Федерация Советының Бюджет һәм финанс базарлары комитеты рәисе:

Җитештерүчеләребез, чит илләргә товар сатып, аларның кулланучылары өчен кирәкле әйберләр булдыру күнекмәләренә өйрәнәчәк. Мондый товарлар илебездә яшәүчеләрнең ихтыяҗларына да туры киләчәк. Импортны алыштыру программасын, чынлыкта, бары тик шулай гына тормышка ашырып булачак.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ТАБИБЛАРГА МӨНӘСӘБӘТ

Сез табибларга ни дәрәҗәдә ышанасыз? Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән шул хакта сорашкан.

**1 – бөтенләй ышанмыйм*
**5 – тулысынча ышанам*





Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫЗДЫРА ҺӘМ КӨЙДЕРӘ

Глобаль икътисад һәм сәясәт фронтыннан уңай хәбәрләр килми диярлек. Халыкара валюта фонды дөнья икътисадының үсешенә кагылышлы фаразларны яңартачагын игълан итте. Әле күптән түгел генә ясаганнары искерде инде. Яңалары начараю һәм түбәнәю турында булачак.

Глобаль рецессия башланмады әлегә, әмма үкчәгә басып килә. Икътисадчы аналитиклар аның якын арада башлану ихтималын 50 процентка тиңлиләр. Инфляция базарларның бугазыннан ала. Аеруча азык-төлек бәяләре куркыныч темплар белән үсә. Ачлык куркынычы арта. БМО Генераль секретаре Антониу Гутерриш дөнья базарларына Россия һәм Украина ризыкларын, Россия ашламасын кайтару чараларын күрергә чакырды. Ул 2022 елда күп кенә төбәкләрдәге ачлыкны шулай гына җиңеп була дип саный.

2022 ел уңышы исә күпчелек илләрдә зур куркыныч астында: чәчүлекләр кызу кояш астында көя. Эсселек бик күп төбәкләрдә зур проблемага әверелде. Менә телефонга килгән иң соңгы хәбәр: Бөекбритания Корольлек Хәрби Һава Көчләренең иң зур базасында очышларны туктаттылар, чөнки очу полосасы туры мәгънәсендә эри. Германиядә Рейн елгасы саекты. Аның буенча электр станцияләренә ташкүмер ташып булмый башлады. Илдәге кояш станцияләре исә, аномаль эсселек сәбәпле, энергия җитештерүнең тарихи рекордын куйды. Әмма кызу һава җил энергиясе ярдәмендә электр җитештерүне бик нык киметте.

Планетаның яңа максимумга җитеп кызуы турында хәбәр Испаниядән дә алынды. Бу илдә Африка чүлләрендәге һава торышы хөкем сөрә. Соңгы көннәрдә кызудан 237 кешенең гомере өзелгән. Термометр угы, +45 градуска җитеп, рекорд куя. Сәламәтлек саклау министрлыгы быел тулаем алганда 829 испан кешесенең эсселектән һәлак булганын хәбәр итте. Бу – эсселекнең беренче дулкыны нәтиҗәләре генә әле. Вальядолидта (төньяк-көнбатыштагы испан шәһәре) күгәрченнәр, яр карлыгачлары һәм хәтта ләкләкләр дә, очып барганда үлеп, асфальтка коела.

Бөекбританиядә сишәмбе кызулыгы 40 градуска җитә. Дымлы һава шартларында 30 градуска да чыдау кыен, диләр. Португалиядә һәм Хорватиядә урман янгыннары котырына. Үткән җомгада Италиянең төньягындагы Бибион курортында ял итүчеләргә, янгыннан котылу өчен, Әдрән диңгезгә сикерергә туры килде. Грециядә янгын сүндерүчеләр бер тәүлеккә илледән артык чакыру алалар.

Кытайда да рекордлы температура. Кызулык Шанхайны, Сычуань провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешен, көнчыгыш Кытай провинцияләре Цзянсу һәм Чжэцзянны иңләп алды. Бер миллиардтан артык кеше интегә. Заводларга электр энергиясен чамалап тотарга әмер бирелде. АКШта кукурузның башакланган чагы, тик ул аномаль кояш астында көя. Бу хәл уңышка тискәре йогынты ясаячак, диләр. Быел иген уңышы бары тик Россия һәм Кытайда гына канәгатьләнерлек булыр дип фаразлана.

Энергия чыганакларына бәяләр үсүдән туктамый. Бу да барлык төр товарларның, бигрәк тә азык-төлекнең бәясен күкләргә чөя. Германиянең эчке эшләр министры Нэнси Фаезер илдә протестларның радикальләшүен белдерде.

Россиядә

ЧИТТӘ БӘХЕТ ТАПСАМ...

Глобаль тетрәнүләр һәм кайнарлык фонында Россиядә хәлләр ярыйсы әле. Бездә дә кыздыра, әмма җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява. Энергия чыганакларына да бәяләр алай ук каты тешләми. Без әле дефляциядән качарга омтылабыз. Ләкин санкцияләр кыршавы каты кысып, аерым товарларга безнең кесәләр өчен авыр булган бәяләр урнаштыра.

Сөмбаш (семга) һәм форель балыкларына бәяләр тапкырлап үскән икән. Россия җитештерүчеләре бу балыкларга ихтыяҗның өчтән берен генә канәгатьләндерә. Балык үрчетү янә импортка килеп терәлә: генетик материал чит илләрдән алына. Сөмбаш ашарга теләсәң, бер килога өч мең сумыңны чыгарып салырга туры килә, диләр.

Затлы балыктан башка да яшәп була булуын. Иң мөһиме: тотрыклылык кына саклансын. Россия Президенты Владимир Путин атна башында үз имзасы белән күпсанлы законнарны гамәлгә кертте. Кануннар арасында тормышны җиңеләйтә торганнары да бар, күңелгә вәсвәсә кермәсен өчен, яшәешне билгеле бер кыса арасына куып кертеп, аерым чикләрдә генә гамәл кылу иреге калдыра торганнары да җитәрлек. Хәзер уйламыйча әйтелгән сүз, үлчәми кылган гамәл өчен озак вакытка рәшәткә артына китүең бик тиз. Федераль хөкүмәт газетасының сишәмбе санында Путин имзалаган законнарның исемлеге бар. Танышып чыгу мөһим, чөнки законны белмәү җаваплылыктан коткармый.

Уңай яңалыклар кысасындагы бер хәбәр: Хезмәт министрлыгы яшьләрнең эш эзләгәндәге мобильлеген тәэмин итә торган программа эшләде. Россиядә бит кайбер төбәкләрдә эшче куллар кирәгеннән артык, кайберләрендә көндез чыра яндырып та эшкә кеше таба алмыйсың. Министрлык эшче куллар артык булган һәм җитешмәгән төбәкләрнең исемлеген төзеде. Санкцияләр нәтиҗәсендә 113,5 мең коммерция предприятиесе эшен туктаткан. Бары тик 78,6 мең генә яңа компания теркәлгән. Дөрес, ябылды дип исәпләнгән компанияләр арасында кәгазьдә теркәлеп, гамәлдә булмаганнары да җитәрлек икән. Бер көнлек фирмалардан чистарту нәтиҗәсендә дә ябылган бизнес саны күп булып күренә. Әмма шунысы да хак: эшсез калып, эш эзләүчеләр саны арта һәм алдагы айларда тагын да артачак.

Хезмәт министрлыгы эшләгән программа карьера ясау өчен бер төбәктән икенче төбәккә күчүчеләрнең хәлен җиңеләйтә. Сиңа әле 35 яшь тулып узмаган икән, рәхәтләнеп программадан файдалана аласың. Кулыңа 116 мең 800 сум акча тоттырачаклар. Хәзерге шартларда бу күп түгел, билгеле, әмма яңа урынга барып урнашу чыгымнарын, беренче атналарда фатир арендалау мәшәкатен капларга җитә. Мәскәүгә яисә Санкт-Петербургка күчкән өчен андый акча бирмәсләр, әлбәттә. Министрлык Россиядә эшче куллар җитешмәгән 25 төбәкнең исемлеген булдырган. Акча алу өчен тагын синең эшсез булып теркәлгән булуың һәм эшче куллар артык булган төбәктә бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә яшәвең дә таләп ителә. Җайлы гына акча тоттырмыйлар, шуңа да кузгалганчы программаның нечкәлекләре белән яхшылап танышырга кирәк.

БЕРАЗ АКСАГАНБЫЗ...

БДИ нәтиҗәләре

218 укучы 100 балл туплаган, 77се аттестатсыз калган, 3 укучы шпаргалка белән тотылган... Быелгы БДИда кыскача картина шундыйрак. Моңа кадәр тәнкыйть утына тотылган Югары Ослан районының үргә менүенең сәбәпләре нидә? Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта республика мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин чыгарылыш укучыларының белеменә бәя бирде.

Быел ил күләмендә рус теле, физика, биология, информатика, география, рус әдәбиятыннан БДИның уртача күрсәткечләре түбәнрәк. Аның каравы профильле математика, химия, тарих, инглиз теле, җәмгыять белеме сынауларында алга китеш бар. Республикада да вазгыять шул чама.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бердәм дәүләт имтиханнарында барлыгы 17452 кеше катнашса, шуларның 16153е – мәктәпне быел тәмамлаучылар. Бездә узган ел белән чагыштырганда физиканы – 1518, химияне – 694, җәмгыять белемен – 584, биологияне 470 кешегә азрак сайлаганнар. Профильле математиканы тапшыручылар да 2000гә кимегән. Рус теленнән уртача күрсәткеч –72,82. Узган ел 74,73 булган. Әлеге фәннән иң югары нәтиҗәне Бөгелмә (78,33) укучылары күрсәтсә, иң түбәне Кайбыч (62,53) районына туры килә. Профильле математика күрсәткече – 64,06, ил күрсәткечләреннән 8 баллга күбрәк. Математиканы иң яхшы белүчеләр Югары Осланда яшәсә (76,49), әлеге фәнгә күбрәк Ютазы (49,37) укучыларының теше үтмәгән. Җәмгыять белеменнән иң югары нәтиҗәләрне – Саба, иң түбәнне Апас районы укучылары күрсәткән. Иң югары баллар инглиз (80,39), француз (80), рус (72,83), немец телләренә (70,79) туры килсә, химия (61,76), физика (59,34), биологиядән (56,78) тырышырга кирәк әле.

– Югары Ослан районын иң югары дәрәҗәгә ирешкән дип артык мактамас идем. Монда проблемалар җитәрлек. Алар безне тыңлый торгандыр, үпкәләмәсеннәр. Монда Иннополис мәктәбе бар. Шулар хисабына нәтиҗәләр дә югары, – диде министр, әлеге районны күккә чөймичә.

Шул вакытта Арча, Әтнә, Актаныш кебек районнар укучыларының күрсәткечләре яхшы булу күзгә ташланды. «Татарча уйлап, фикер йөртеп, русча имтихан тапшырган татар районнарының чыгарылыш укучылары безне сөендерә. Татарча уку синең белемең ким була дигән сүз түгел. Әти-әниләр шуны аңласыннар иде», – дип ассызыклады Илсур Һадиуллин.

Барлыгы 218 укучы 100 балл җыйган. Шуларның 14е ике фәннән абсолют нәтиҗәгә ирешкән. Август аенда бер фәннән йөз балл җыючыларга – 15, бу күрсәткечне ике тапкыр арттыручыларга 25 мең сум акча биреләчәк. Югары балл туплаучы укучылар – Югары Ослан, Саба, Бөгелмә, Казанның Вахитов һәм Идел буе районнары, Лениногорск, Яшел Үзән кебек районнардан. Мондый сәләтле балаларның иң күбесен Казанның 131 нче лицее (306), Чаллының 78 нче мәктәбе (261), КФУның Лобачевский исемендәге лицее (196) әзерләгән. Шул ук вакытта 77 укучы аттестаттан коры калган. Бу – барлык укучыларның 0,48 проценты. Узган ел 40 укучы аттестат алмаган. Көз көне аны кабат тапшырырга була. Тик бу мөмкинлектән йә рус теле, йә математикадан бер «2ле»се булганнар гына файдалана ала.

Өендә белем алган биш укучы сынауга бөтенләй килмәгән. Монысы – икенче проблема.

– Татарстанда гаиләдә укуны сайлаучылар саны арта бара. Аларның бишесе куркып, имтихан тапшырырга килмәгән. Бу – бер елларын югалттылар дигән сүз. Ни өчен килмәгәннәр, алар нәрсә уйлый? Әгәр мәктәптә арадаш аттестацияне тапшырган булсалар, мондый проблема килеп чыкмас иде, – диде Илсур Һадиуллин, мәктәптә белем алуны хуплап.

Министр профильле сыйныфларның тиешле дәрәҗәдә кулланылмавын да ассызыклап үтте. Мәсәлән, Тәтеш районында укучыларның 45 проценты җәмгыять белемен сайлаган, тик моңа туры килгән профиль бөтенләй оештырылмаган. Профильле сыйныфлардагы түбән күрсәткечләр дә, фәннәрне тирәнтен өйрәтү өчен сыйныфлар ачу мәсьәләсе дә контрольгә алыначак.

Илсур Һадиуллин итагатьлелек саклап, имтихан кагыйдәләрен бозучыларны фаш итәргә ашыкмады. Шпаргалка куллану аркасында узган елдагы кебек өч укучы имтиханнан чыгарылган. Әлеге укучылар үзләренә үпкәли, быел вузга укырга керә алмаячак.

Сәрия МИФТАХОВА

Исемендә – җисеме

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Снежана белән Михаил исә 4 июльдә туган кызчыкларына Вилена һәм Ева дигән исемнәрне сайлаганнар. «Православ исемнәре булсын дидек», – ди әти кеше. УЗИ тикшеренүе үткәндә, ул хатыны янәшәсендә булган. Снежана башта, «ничек күтәрермен» дип, шок һәм курку хәлендә калган. Олы уллары, 11 яшьлек Данилга исә диңгез тубыктан: ике чәчкә шикелле ике сеңлесенә карап, үзен чып-чын абый итеп хис итә ул, йөзендәге горурлыкны күрсәгез!

Снежана – стилист-мерчендайзер булып эшли, Михаил – төзелеш фирмасында. Алар янәшәсендә дә, бар шатлыкны һәм авырлыкны бүлешергә әзер булып, бәхетле дәү әни басып тора.

Сабыйларга таныклык тапшырганда, Татьяна Ларионова, аларны һәм әти-әниләрне котлап, үзенең җылы теләкләрен җиткерде. «Мондый исем кушу чарасы һәр шәһәрдә һәр гаилә өчен булырга тиеш дип саныйм. Бәхетле сабыйлар булсыннар! Кызганыч, статистика буенча, Россиядә бала туу саны кими. Бу җәһәттән Казан һәм Чаллы күпбалалы гаиләләре белән үзенчәлекле», – диде ул.

Быел алты ай эчендә Чаллыда 2946 бала туган. Шуларның 22 пары – игезәкләр. Аз туалар дип чаң сугалар шул. Бала тууны арттыру өчен, дәүләт әллә нинди чаралар тәкъдим итеп карый. Демографик сәясәт концепциясен тормышка ашыру өчен, 7 бүлектән торган план да төзелгән. Ул план эчендә традицион гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру аерым урын биләп тора. Әллә кайбер яшь гаиләләр «традиция»ләрне белеп кенә бетермиләр микән соң, аптыраган инде...

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

Яшәргә өйрәнәбез

Эшмәкәргә ни җитми?

Эшмәкәрләргә үз эшләрен алып барыр өчен мөмкинлекләр җитәме? Алар нинди проблемалар белән яши, нинди каршылыклар белән очраша? Кичә «Бердәм Россия» партиясе төбәк иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә Дәүләт Думасы депутаты Әлфия Когогина «туры элемтә» үткәрде. Очрашуда кече һәм урта эшмәкәрлек, Татарстанда тормышка ашырылучы дәүләт программалары хакында сөйләштеләр.

Әлфия Когогина әйтүенчә, дәүләт эшмәкәрләргә йөз белән борылды, ди. Быелның гыйнварыннан җәмәгать туклануы өлкәсендә эшләүчеләрне НДСтан, 1 июльдән кайбер төр бизнес вәкилләрен декларация тапшырудан азат иткәннәр.

– Эшмәкәрләр өчен федераль дәрәҗәдә ярдәм чаралары күрелә. Ташламалы кредит программасы, кредит «каникул»лары шактый ярдәм итте, – диде ул.

«Татарстанда эшмәкәрләргә ярдәм итү фонды» җитәкчесе Айдар Салихов эшкуарларга Татарстанда күрсәтелә торган ярдәм чараларына тукталды. Аның сүзләренчә, пандемия һәм илдәге вазгыять аркасында, эшмәкәрләргә ташламалы микрозаемнар бирелгән, алар түбән ставкалы кредит ала алганнар. Хәзер күп кенә бизнес вәкилләре кредит алу эшләрен дә цифрлы платформа аша башкара икән.

– Республиканың 45 районында да эшмәкәрләрне кайгырту фонды вәкилләре бар. Алар һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Эшмәкәрләр яки үз эшен башларга теләүчеләр 8 (843) 524-90-90 телефон номерына шалтырата ала. Дәүләт хезмәтләре порталы аша да үзенә кирәкле чараларны таба ала. Әгәр эшмәкәр эзләгән вакытта берәр хезмәт ачылмый икән, эшли башлагач, электрон почтасына хәбәр килә. Без эшмәкәрләр белән гел элемтәдә торабыз, – ди Айдар Салихов.

Татарстан Президенты каршындагы вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү буенча эшмәкәрләр хокукларын яклау бүлеге мөдире Глеб Макаров исә максатлары – эшмәкәрләрнең хокукларын яклау булуын белдерде:

– 2020 елда эшли башлаган «кайнар линия»гә 31 меңнән артык мөрәҗәгать килде. Берәүләр дәүләттән ярдәм ала алмавыннан, икенчеләр салым буенча, өченчеләре үзләре кебек эшмәкәрләрдән зарлана. Эшмәкәрләрне үз товарларын читкә чыгара алмау, импортны алыштырудагы кыенлыклар да борчый. Әмма бергәләп эшләгәндә, без проблемаларны чишү юлларын табабыз. Ташламалы микрозаем алу программасы да башта ике елга гына исәпләнсә, тагын бер елга озайтылды. Бу да – ярдәм бит, – ди ул.

Очрашуда товар сатучы белән аны алучы арасында килеп чыккан аңлашылмаучанлык хакында да сөйләштеләр. Әлфия Когогина, бүгенге вазгыятьтә бер-береңне аңларга кирәк, дип киңәш бирә.

– Элек үз продукциясен читкә чыгарган эшмәкәрләргә юл ябылу да зур кыенлык тудырды. Әмма аннан чыгу юлларын карыйбыз. Иран, Һиндстан белән хезмәттәшлекне ныгытабыз, – ди ул.

Татарстан эшмәкәрләренниләр борчый соң? Дәүләт Думасы депутаты әнә шул хакта кат-кат сорашты. Баксаң, алар көнкүреш калдыкларын чыгару проблемасы белән дә еш очраша икән. Күптән түгел төбәк операторлары белән бу хакта сөйләшкәннәр дә инде. Күпләр дәүләт хезмәтләре сайтының начар эшләвеннән зарлана. Очрашуда моны да хәл итәргә килештеләр. Шулай ук кредит алганда, эшмәкәр банкка залог калдырырга тиеш икән. Белгечләр, барлык эшмәкәр дә моны эшли алмый, ди. Мисал итеп, дару үләннәре белән шөгыльләнүче кешене китерделәр. Ул банкка залог итеп, кәрҗинен куйсынмы, диештеләр. Киләчәктә бу хакта да уртак фикергә килергә сүз бирделәр.

Эшмәкәрләр дәүләттән ни көтә? Аларга иртәгәге көнгә ышаныч кирәк. Шуңа да үз юнәлешләрендә ныклы гарантия булуын тели. Кадрларны укыту мәсьәләсен дә кайгыртырга кирәк. Эшмәкәр булам диюче күп, әмма эшне нидән башларга белмәүчеләр дә җитәрлек икән. Элек дәүләт, эшмәкәрләргә сатып алган җиһазларының ярты бәясен кире кайтарып, компенсация бирә торган булган. Бизнес вәкилләре шул программаның яңадан эшләвен тели.

Очрашуда кызыклы фикерләр, төрле тәкъдимнәр дә, сораулар да күп булды. Әлфия Когогина аларны өйрәнеп, һәркайсына җавап бирергә вәгъдә итте:

– Эшмәкәрләр проблемасын һәрдаим белеп, сорауларына җавап биреп, аларга ярдәм итеп торырга кирәк. Киләчәктә без бу сөйләшүләрне дәвам иттерербез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ЯШЬ ЭКОАКТИВИСТ АЛЬБЕРТ ГАБДЕЛФӘРТОВ:

«Табигатьне саклау өчен теләк кенә җитми»

Табигатьне саклау өчен теләк кенә җитми. Әлмәттә яшәүче 4 нче сыйныф укучысы Альберт Габделфәртов әнә шулай ди. Яшь экоактивист белән табигатьне саклау һәм экологик проектлар турында сөйләштек.

Әлмәттә узган Нефть саммиты кунаклары һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда Альберт пластик шешәләрнең капкачларын җыю тәкъдиме белән чыккан иде. Кулланылган батареялар өчен бокслар, кибет һәм мәктәпләрдә пластик капкачлар өчен аерым контейнерлар урнаштыру, алардан кергән табышны хәйрия фондларына юнәлтү – экологияне кайгыртучы яшь активистларның идеяләре әнә шундый. Альбертның кызыксынучанлыгы, төрле сораулар бирүе Рөстәм Миңнехановның игътибарын җәлеп итте. Нәтиҗәдә Альберт Әлмәт районы башлыгының экология буенча киңәшчесе итеп билгеләнде.

– Өч ел элек мин пластик шешәләрнең капкачларын җыю буенча проект эшли башладым. Контейнерларны өйдә, өй тирәсендә, мәктәптә куйдым. Тик бу гына аз иде. Шуңа күрә Нефть саммитында мин Әлмәт башлыгына шәһәр буенча пластик капкачлар өчен контейнерлар урнаштыру идеясен әйттем. Бу фикерне Тимур Дмитриевич та, Президент Рөстәм Миңнеханов та ошатты, – дип сөйләде Альберт.

Пластик шешәләрнең капкачларын җыю идеясе ничек барлыкка килгән соң? «Мәктәптә кул эшләре белән шөгыльләнгәндә, артык капкачлар кала иде. Шуларны җыеп, «Игелекле капкачлар» фондына тапшыра башладык, – ди Альберт. – Ел саен тугыз миллион тоннага якын пластмасса дөнья океанына эләгә. Пластик шешәләрнең капкачларын йотып, балыклар гына түгел, җирдәге хайваннар да үлә. Капкачларны сатудан кергән акча сәламәтлекләре чикләнгән һәм ятим балаларга ярдәм күрсәтүгә тотыла. Шул рәвешле, без табигатькә дә, балаларга да ярдәм итәбез. Кешеләргә файдалы экологик гадәтләр җитми. Бер кечкенә генә гамәл дә планетада яшәүче һәркем өчен әһәмиятле».

Альберт халыкны файдалы гадәтләргә өйрәтеп буласына чын күңелдән ышана:

– Мин психология буенча видеолар карарга яратам. Бер көнне бер кызыклы видеога тап булдым. Анда кешедә табигатьне саклауга бәйле файдалы гадәтләр булдыру турында сөйләнде. Әйтик, кеше көненә берничә тапкыр шешә капкачын чүплеккә түгел, ә контейнерга салса, ул даими рәвештә шулай эшли башлаячак. Гадәткә керсен өчен, пластик капкачны ким дигәндә 60 тапкыр контейнерга салырга кирәк.

Яшь экоактивист мәктәптә, шәһәрдә экологияне популярлаштыру буенча идеяләре белән дә уртаклашты:

– Пластик капкачлар җыю проектыннан тыш, без бу темага мәктәпләрдә сыйныф сәгатьләре үткәрергә телибез. Кешеләргә моның ничек мөһим булуын аңлатып, аларда да яхшы гадәтләр барлыкка килүен телим. Мин мәктәпкә гел шешәләр, капкачлар, кәгазь алып килеп тапшырам. Гаиләм белән табигатькә чыкканда да ташланган чүп-чарны җыябыз, әйләнә-тирәне чистартабыз. Табигатьне саклау өчен теләк кенә җитми, эшләргә кирәк.

Ә үскәч, ул биоинженер булырга тели. Кешеләргә ярдәм итү өчен төрле приборлар булдырасым килә, ди. Экологиягә ярдәм итүеннән дә туктарга җыенмый.

– Табигатькә ярдәм итүнең ысуллары күп. Шешә капкачларыннан тыш, кәгазь, тимер тапшырырга була. Әлегә мин пластик капкачлар җыюга тукталдым. Моннан тыш та тормышка ашырасы проектларым бар, – ди экология сагында торучы.

Ләйсән САФИНА

УНБЕР ХУҖАЛЫКЛЫ, ИКЕ ИСЕМЛЕ

Ни хәлең бар, авыл?

Унбер хуҗалыклы авыл дигәндә, ышанам, күпчелегебезнең күз алдына үлеп баручы авыл килә. Җимерек йортлар, караучысыз каралтылар, чүп үлән басып бетергән бакча урыннары… Дөресен әйтим, Балтач районының иң ерак чигенә урнашкан бу авылга барганда мин дә башка төрле картина күрермен дип уйламаган идем. Баксаң, фермасыз, кибетсез, мәктәпсез, ФАПсыз, кыскасы, бернәрсәсез авылда да гөрләтеп яшәп була икән. Иске Пукшинер әнә шундый үзенчәлекле авыл булып чыкты.

Автор фотосы

Ике исемле бу авылга заманында марилар нигез салган була. Әле бу гасыр башына кадәр авылда мари гаиләләре яши. Алар берәмберәм күчеп китеп бара, авылда йортлар саны да шуңа бәйле рәвештә кими. Авылның икенче исеме – Ушла (иң кызыгы: халыкта аны күбрәк шушы исеме белән беләләр) да әнә шул марилар белән бәйле дигән риваять яши. Балтач районы энциклопедиясен төзегән Гарифҗан абый Мөхәммәтшин әйтүенчә, «Пукшинер белән янәшә генә булган Сәрдек авылына ниндидер максат белән килгән рус чиновниклары, авылда мариларның булмавын күреп, монда төпләнгән татарлардан аларның кая китүен төпченгәннәр. Русчаны ипилек-тозлык кына белгән татарлар, Иске Пукшинер ягына күрсәтеп: «Ушла! (киттеләр)», – дип җавап биргәннәр. Әлеге чиновниклар авылның исемен Ушла дип теркәп тә киткәннәр. Җиңел яңгырашлы исем халык теленә дә тиз кергән…»

Җирле үзидарәдән алынган мәгълүматлар буенча, бүген авылдагы унбер хуҗалыкта 33 кеше яши. Шуларның 9ы – пенсионер, дүртесе мәктәп яшендә. Авылның иң өлкән кешеләренең берсе Рәкыйп абый Фәйзуллин авылның 42–43 өйле чакларын да яхшы хәтерли.

– Авылда фермалар күп иде. Аларда бөтен төрле мал да асралды. 50 атлык ат дворы гына бар иде. Сыер, үгез, таналар, сарык, дуңгыз, куян… Тавыкка кадәр асрадылар. Кечкенә булса да кибет бар иде. Элекке мулла йортында бер ягында башлангыч мәктәп, икенче ягында кечкенә генә уку йорты эшләде, шул клуб ролен үтәде. Авылда күпчелек марилар иде. Гомумән, бездә ул чакта ук бик тырыш кешеләр яшәде. Шуңа күрә тормышлары начар булды дип әйтә алмыйм. Өч ындыр гына бар иде. Берсен Зиннәт ындыры дип йөрттеләр, икесе мариларныкы иде. Без үскән елларда авылда бала-чага күп булмады, мари гаиләләрендә алар аз иде, без исә дүрт бала үстек. Башлангычны авылда укысак, аннан күрше-тирә авылларга җәяү йөреп белем алдык. Авыл нәрсәгә бетте дисеңме? Хөкүмәтнең сәясәте дөрес булмаганга. Вакытында авылларга аз гына ярдәм булса, яшьләр китми иде, – ди ул.

Шунысы да бар: Ушлада соңгы егерме елда йортлар саны 11дән кимеми. Үзләре әйткәндәй, гел бертөрле тора: артмый да, кимеми дә. Бу кадәресе – авылда әле яшим дип яши торган, эшле дә, ашлы да кешеләр яшәгәнгә бер дәлил, миңа калса. Бер урамлы бу авылның бер очыннан икенче очы күренеп тора. Үзләре авылның теге очында дип сөйләшсәләр дә, капка төбенә чыгып бассаң, бөтен кешегә кул болгарга, береңне берең күрергә була. Авыл искитмәле табигать почмагына урнашкан. Пукшинер сүзенең беренче өлеше «пукшы» маричадан елгалар кушылган җир, култык дип аңлатылса, тагын бер варианты «пүкше» чикләвеклек, куаклык дип тәрҗемә ителә икән (Балтач энциклопедиясе). Ушлага икесе дә туры килә. Йортлар, каралтылар чәчелеп урнашмаса да, тормыш итәр өчен бик уңайлы итеп «сузылганнар» – артка таба (ни дисәң дә, урын иркен), бакча, ихата өлешләренә зурайганнар. Күп итеп терлек, кош-корт асрыйлар. Һәр йортта диярлек икешәр сыер. Өчне, бишне асраучылар да бар. Ике хуҗалыкта сигезәр сыер, диделәр. «Электр көтүче»ләре дә бар, анда сигез сыер гына тора, калганнарын, урын иркен дип, арканга йөртәләр. Сөтне көн саен күрше авылдан килеп җыялар, атнага бер көн күчмә кибет килә, барыбызда диярлек машина, кирәк әйберне үзебез дә барып алып кайтабыз, атнага бер көн чүпне җыйнап алып китәләр, юлларыбызны юллар идарәсе даими чистартып тора, диләр. Юллар бу авыл өчен гомергә зур проблема булган. Ә хәзер, мәктәп укучыларын автобус Пыжмара мәктәбенә йөртә башлагач, юллы да булганнар, юллары караулы да. Почта вакытында килә, пенсияне китереп бирә, түләүләрне алып китә, дип, Сәрдек хат ташучысы Флера Гомәрованы, шул авылның ФАП мөдире Лилия Гайнуллинаны исә, чакыруга менеп җитә, дип мактадылар. Телефон элемтәсе белән дә проблема юк икән: «Летай», «Мегафон», «МТС» тота, җәйләрен су коенам дисәң, күрше Сәрдектә генә плотина бар, газ, су кергән, диләр. Авылда гомергә Сабан туе үтмәде, әмма якынтирәдә генә әллә ничә авыл, барысына да барырга була, диделәр. Әнә шулай, тормышларын һәр яктан җайланган, көйләнгән итеп, яратып сөйлиләр биредә. Яшьләр калмый, яшьләр китә, бетүгә барабыз, дип кенә кайгыралар.

Авылда бер ир-егет «Кама» хуҗалыгында механизатор булып эшли. Тагын өч хатын-кыз – күрше авылларда бюджет өлкәсендә, калганнары үз хуҗалыгында эшли һәм пенсиядә. «Кама» хуҗалыгына карасалар да, күбесе заманында пай җирләрен алган. Кемдер үзе эшкәртсә (зур мәйданнарда печән җирләре булу терлек асрауны җиңеләйтә), авылның төп терәге булган фермерга арендага бирүчеләр дә бар. Җирләре, техникасы, пилорамасы булган Рамил Фазуллин – авылның төп терәге һәм таянычы. «Нинди генә үтенеч булса да, аңа әйтәбез, бөтенесен хәл итә, авылыбызның ике чишмәсен дә матурлап эшләтеп куйды», – диләр. Авылда яшәүчеләр күптән инде үз көннәрен үзләре күрергә гадәтләнгән. Тырыш хезмәтнең нәтиҗәсе дә күз алдында: берсеннән-берсе зур, матур, төзек каралтылар балкып утыра. Биредә беркемнән дә ул юк, бу юк дигән моң-зарны ишетмәдем. Киресенчә, бөтен эшне яратып эшлиләр кебек тоелды. Үземә дип тырышкан көннәре.

– Төп йортны бетермик, нигез таркалмасын, дип калган идек, кырык ел шушы авылда яшәп ятабыз, – ди зур Түнтәр авылыннан бирегә килен булып килгән Наилә.

– Авыл барыбер сагындыра, атна саен кайтам, – ди Арча педколлиятенең беренче курсын тәмамлаган Зәринә. – Кайтканда попутка белән йөрим, киткәндә, интернеттан белешәбез яки авылныкылар туры килә…

Авылдагы унбер хуҗалыкның бишесендә Фазулла нәселе яши. Урамнары да Дуслык исемен йөртә аларның. Тикмәгә түгел бу…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Россия сәнәгать хезмәткәрләре һөнәр берлегенең «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте башлангыч һөнәр берлеге оешмасы рәисе **Антипов** Константин Сергеевич; Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары **Гайзатуллин** Ринат Рәүф улы; хезмәт ветераны **Житин** Анатолий Иванович; Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 8 номерлы эксперт составы җитәкчесе – медицина-социаль экспертиза буенча табибы **Кореева** Марина Викторовна; хезмәт ветераны **Вагин** Альберт Петрович; Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы **Габдерәшитов** Булат Рәшит улы; хезмәт ветераны **Шырыбыров** Александр Григорьевич; җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Новикова** Валентина Сергеевна; Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы полиция полковнигы **Хөснетдинов** Роберт Шәрифҗан улы; Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен Бөек Ватан сугышында катнашучы **Порсева** София Яковлевна; Бөек Ватан сугышы ветераны **Пронин** Алексей Михайлович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Чүпрәле район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең ветеринария табибы-серологы **Бахитова** Зөбәрҗәт Абзалетдин кызына, «Апас район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Гыйбадуллин** Алмаз Нәҗип улына, «Үзәк фәнни-методика ветеринария лабораториясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан сынау лабораториясе серология һәм лептоспироз бүлеге ветеринария табибы **Мәдъярова** Мөнирә Әмир кызына, «Арча район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Түбән Аты участок ветеринария пункты мөдире – ветеринария табибы **Фәйзрахманов** Фидарис Васил улына, «Әтнә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы урынбасары – эпизоотиягә каршы көрәшү эше буенча ветеринария табибы **Шагиев** Сәлих Габдрахман улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК
«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

БЕР ТИЕНСЕЗ ЭШ БАШЛАГАН ФАИЛ ХӘКИМОВ:

«БАЙ КЫЗЫНА РӘХМӘТ!»

Арча районының Орнашбаш авылы егете 26 яшьлек Фаил Хәкимов белән көтмәгәндә таныштык. Чираттагы сәфәребезгә баруыбыз иде. Юл буена туктап, каһвә алырга уйладык. Казан – Балтач арасында йөрүчеләр бу урынга туктамый китми, диләр. Иртәнге алты гына тулып киткән булса да, Фаил эш – тирә-якны матурлау белән мәшгуль иде. Газетадан икәнне белгәч, елмаеп ук җибәрде: «Ватаным Татарстан»ны укып бара икән.

– Эшкә уйламаганда тотындым. Әзрәк юләрлек тә бар инде, – дип шаярта ул. – Армиядә вакытта йөргән кызым ташлады. Бай иде ул. Кызымның ташлавы рәхәт булмады. Күңел төшкән чаклар да күп булды. Әмма мин ничек тә бу кыздан өстен булам әле дип яши башладым. Ничек кенә борынына чиртергә соң? Бер ел буе шул хакта уйландым. Кайтуга, каһвә сата торган нокта ачам, дидем.

Туган якка кайткач, Фаилнең уендагы беренче сорау «Сату ноктасын кая куярга?» була. Ул эзләнә башлый. Кешеләргә каядыр кереп түгел, машина белән туктап кына кофе алу отышлырак дигән фикергә килә.

– Мин аны тиз генә барып чыгар дип уйладым. Янәсе, киоск урнаштырам да сату китә. Булган, ди, пычагым! Әле үземнең машинам да юк бит. Хәзер уйлап торам да шаккатам. Нинди йөрәк булгандыр үземдә?! Киоскны куярга да акчам җитмәде. Шуннан соң Казанга эшкә киттем. Белемем булмаса да, пешекче булып урнаштым. Ашарга әзерләргә яратам мин. Бер ашханәдә ике көн эшлим, ике көн ял итәм. Ә акчаны әйбәт түлиләр. Ул чакта 50шәр мең ала идем. Тырыша торгач, эшне башлап җибәрдем, – ди ул. – Каһвәне үзем сата башладым. Көтмәгәндә әти-әнием миңа сюрприз ясады. Машина алып бирделәр. Калганын үзең булдырырсың, дип тә өстәделәр. Беренче вакытларда җиңел булмады. Башны ташка бәрердәй чаклар күп булды. Әмма бирешмәдем. Күңелсезлек саен бай кызын искә төшерәм. Әллә кайдан көч кереп киткәндәй була. Көнгә 200–300 сум акча эшли идем. Әнигә рәхмәт, кофе янына камыр ризыклары пешереп бирә башлады.

Фаил үзенең эш башлаганын беркемгә дә әйтми. Берзаман бу хакта дуслары ишетеп ала һәм аңа ярдәм итә башлый. Ничек итепме? Казаннан машиналарына төялеп кайтып, каһвә эчәләр икән. Әнә шуннан соң бу урынны дусларның дуслары да белә башлый. Тәмле каһвәнең кайда сатылуы «сарафан радиосы» аша тарала. Хәзер инде Фаил шөкер итә. Яраткан эше акча да китерә башлаган. Әмма егет моның белән генә туктап калырга җыенмый. Авылда буш яткан җирләре бар икән. Ул шуларга тотынмакчы.

– Җирдә эшләп, акчалы булуны башкаларга күрсәтәсем килә. Бөтен кешегә дә шәһәргә күчәргә димәгән бит инде. Мин үз юлымны туган ягымда таптым. Ялкауланмаска гына кирәк. Тырышлык булса, әллә ниләр эшли аласың икән. Минем очракта үҗәтлек тә ярдәм итте. Әгәр бай кызы ташламаган булса, мин бүгенге кебек бәхетле булмас идем, – ди Фаил. – Тиң ярымны таптым мин. Хыялда йөрткән, нәкъ миңа кирәк кыз күрше авылда гына булган икән бит. Җылы сүзе, төпле киңәше белән күңелне үстереп тора. Күптән түгел гаилә корып җибәрдек. Тормыш юлыннан икәү атлый башлагач, әллә ниләр эшләячәкбез әле!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы фикере

Пистолет

Менә бу очракта сүзне нәрсәдән башларга икән? Балаларның тынгысызлыгыннанмы, әллә ирләрнең сантыйлыгыннанмы? Белмим инде.

Мин – туксанынчы елларда егет булып әвәләнгән кеше. Кызык чор иде ул. Куркыныч та. Бер мәлне чыгып, киосктан тәмәке алмакчы булдым. Каршыма кечкенә буйлы бер егет чыгып басты. Кулында газ баллоны. Хәзер сиптерәм яки кесәңне әйләндерәсең, ди. Мин бераз чыныккан кеше инде, бот буе малайларга гына бирешеп тора торган түгел. Сугып әйләндердем. Баллоны бер җиргә, үзе икенче якка очты. Сөендем инде үземнең шундый батыр булуыма. Тик шул ук мизгелдә кайдандыр әллә ничә егет килеп чыкты да мине төреп алдылар. «Нигә син кечкенә кешене рәнҗетәсең?» – диләр. Ни дип җавап бирим? Ә аларга җавап кирәкми дә! Тотындылар мине дөмбәсләргә. Сугыш китте. Бер-икесен аудара алдым инде, тик үземә дә ару гына эләкте. Күзлекне ваттылар, аның урынына фингал утырттылар. Ул арада милиция килеп җитте. Мин авыз ачып сүз әйтергә өлгергәнче, болар такылдап тора: «Безнең энекәшне кыйнады, шуны яклашырга чыктык», – диләр. Милиция боларны түгел, мине алып китте. Мин гаепле булып калдым. Таң атканчы үземнең гаепсез икәнемне исбатларга тырыштым да, тәмам хәлем беткәч, чурт с ним, дип бар гөнаһны үз өстемә алып, штраф түләп чыктым.

Түләмичә дә булмый. Милициядә нык ахмак малайлар утырмый бит инде, алар сине паспортың буенча «пробивать итәләр» һәм бөтен биографияңне ачыклыйлар. Ә мин каратэ белән шөгыльләнгән өчен ике ел исәптә торган адәм һәм «кешегә сугарга ярамый» дигән тамга беркетелгән зат идем. Бик оста сугышчы да түгел инде югыйсә. Ләкин заманы шундый: әгәр сиңа тамга сугылган икән, шул тамганың бөтен кабахәтлеген татый торган чор иде. Сугышкан өчен утыртып та куярга мөмкиннәр, ә монда штраф кына… Мин сөенә-сөенә түләп чыктым.

Юк, бер гаепсез көйгә бит ул. Тәмәке алырга гына чыккан җирдән. Дәвере шундыйрак иде аның. Бер мәлне хатын Уфаның тимер юл хастаханәсендә ятты. Мин, күчтәнәчләр алып, аның янына барам. Трамвайда. Чыгуыма бер егет култыклап алды да читкәрәк алып китте. Шул ук нәрсә инде. Пакетыңны бир, кесәләреңне әйләндер… Мин үзем генә белгәнчә моны җиргә сузып салдым. Тик шул ук мизгелдә өстемә килә башлаган егетләрне күреп калдым һәм каратэның иң яхшы алымын сайладым – ул йөгереп качу дип атала. Хастаханә ишегеннән кергәнче кудылар. Хатын белән озак кына сөйләшеп тордык. Мин үземдә булган бөтен акчаны мәҗбүриләп аңа калдырып киттем. «И, ирем әйбәт, и мине ярата», – дип уйлагандыр инде. Ә мин үземне көтеп торачакларын белә идем. Көткәннәр. Сугыштык. Тагын милиция килде. Тагын мине алып киттеләр. Штраф чәпәделәр.

И, мин мондый мисаллар белән дөнья тутыра алам инде. Һәр дәвернең үз «бзик»лары була. Туксанынчы еллар шундыйрак иде. Мин шул вакыйгалар эчендә яшәгәч, улларыма «Иң мөһиме – үз-үзеңне һәм якыннарыңны саклый алу» дигән фикерне сеңдерергә тырыштым. Аларның телләре ачылганчы, аяклары күтәрелә башлады. Төрле көрәшләрдә катнашып, урыннар яуладылар. Мин сөендем. Каратэга юл ачылган иде инде: алар шуның белән шөгыльләнделәр. Кечкенә улым Алмазга бер мәлне үзеннән өлкәнрәк малайлар бәйләнгән дә бу боларны кыйнап ташлаган. Малайны судка бирделәр. Бишенче сыйныф баласын җиденче сыйныфта укыган ике малай рәнҗетергә уйлаган. Алмаз үзен якларга мәҗбүр булган. Ләкин теге балаларның әти-әниләре бай кешеләр иде, тагын минем малай гаепле булып калды. Мин яклый алмадым. Теләмәдем дә. Үз-үзен яклый алган малай минем ярдәмгә мохтаҗ түгелдер сыман тоелды. Шуннан присяжныйларның берсе миңа киңәш бирде:

– Улыгыз шундый энергичный икән, аны спорт белән шөгыльләндерегез. Мәсәлән, каратэ белән…

– Ул – беренче разрядлы, – дип кенә әйтә алдым.

Горурланып әйттем. Үз-үзен яклый белгән малай горурлануга хаклы иде.

Тик мин беркайчан да үземне яклый белмәдем. «Беркемгә дә сукмыйм», – дип уйласам, кыйнап ташладылар, суксам – милиция килеп җитте. Шушы хәлләр тәмам ялкыткач, бер дустым акыллы киңәш бирде: «Пистолет ал син, Марат». Һәм ул үз сүзен дәлилләп тә куйды: «Сиңа пычак чыгаралар яки баллон белән яныйлар. Ә син иплән кенә пистолетыңны күрсәтәсең. Үзенә төбәлгән пистолеттан барысы да куркачак». Дөрес иде бу, бер карасаң. Пистолет ул синең бөтенләй башка дәрәҗә кешесе икәнне күрсәтә торган нәрсә иде. Баллон чыгаручы ул – гади хулиган гына, пычак чыгаручы да әллә кем түгел. Ә пистолет йөртүче – чын бандит, мафиозник. Бандит булу зур дәрәҗә иде.

Һәм мин пистолет сатып алдым. Револьвер. Чиләбе өлкәсенең Мияс дигән җирендә сатып торалар иде. Гастрольдә йөргән чакта акча кызганыч тоелмый ул. Атып карарга да урыннары бар. Револьвер ошады. Ул бала-чага уенчыгына да охшап тора, пистон белән ата торганны аларга алабыз бит инде. Моның авырлыгы гына башкачарак. Пуля юлындагы түгәрәк уртасында торган пластинканы кисеп ташласаң, «мелькашка» патроннары белән дә манчып була. Кистек инде аны. Аттык урманда. Өйгә алып кайттым. Ул дәвердә өйгә дә басып керә торганнар иде. Кемгәдер кереп, үтереп чыкканнар икән дигән хәбәрләр дә йөргәләде. Моның гайбәт кенә түгеллеген мин чамалый идем.

Вәт… Револьверны алып кайттым да, «мелькашка» дигән патроннар белән корып, шкаф өстенә куйдым. Анда беркемнең дә буе җитми инде. Хатынга да әйтеп тормадым. Кирәкмәгәндер дә. Теләсә нинди вазгыятьтә үземә үрелеп алырга җайлы, шул җитә, беркемнең дә белүе мөһим түгел.

Бимазалаучы булмады. Бер мәлгә барысы да онытыла төште. Дөнья да, бәлки, беркадәр тынычлангандыр. Аннан соң мин әллә нинди миллионер да, бандитлар белән уртак эш йөрткән кеше дә түгел бит инде. Өйгә килеп, үтереп китүче юк. Ярлы кешенең әҗәле дә сәер, үзе эзләп барса гына килә. Кесәдә дә пистолет йөртә алмадым, мин, гомумән, коралсыз гына эш итәргә күнеккән кеше икән. Маҗараларга тарып торсам да, тимер кисәге күтәреп йөрисем килмәде.

Бер мәлне өйгә кайтып керсәм, бот буе гына улым пистолет күтәреп килә. Елмая инде үзе:

– Әти, мин сине атам! – дигән була. Мин дә елмаям:

– Ат, улым. Әтиләр үлемсез ул…

Һәм аның кулында уенчык пистолет түгел икәнен чамалап алам. Шайтан таягы малай, ничектер үрмәләп, шкаф өстенә менгән, минем теге револьверны кулга төшергән… Ә ул корылган килеш… Арка үзәгенә салкын йөгерә, тәнгә каз йоны калка. Ул арада кухнядан хатын чыга. Малай пистолетын аңа төби.

– Кайсыгызны атыйм, әни? – ди.

Мин беркайчан да булмаганча курку хәлендә. Бала әле берни аңламый. Үзенең нәрсә эшләгәнен үзе дә аңлый алмаган кеше кулындагы корал һәлакәткә илтергә дә мөмкин. Бөтен дөньяны. Ә безнең бөтен дөнья шушында. Ул елмаеп кына курокка басса, елмаеп кына ятим калачак. Бик каты кагылмаска тырышып, баланың кулындагы пистолетны сугып төшерәм. Малай еларга тотына. Пистолет атмыйча кала. Ходайның бүләге инде бу, ялгышрак төшсә, атылып китәр иде. Ул вакытта ни булачагын кем белгән… Әнисе мине тиргәргә керешә:

– Туйдырдың инде шул хәрәкәтләрең белән. Балага йомшаграк булсаң да ярар иде…

Мин пистолетны алып, патроннарыннан азат итәм. Соңрак мин аны Караидел елгасына атып бәрәчәкмен. Кирәкми. Балалы йортта беркайчан да корал булырга тиеш түгел. Йортта беркайчан да корал булырга тиеш түгел. Түгел… Бу сүзләрне мин ант урынына кабатлаячакмын…

Ул чактан соң бик күп сулар акты. Замана да, мин дә бүтән инде. Ә каратэ… Ул «буш кул» дигәнне аңлата. Мин спортны ташласам да, гомерем буена каратист булдым бугай, бөтен үрләремне буш кул белән яуладым. Һәрхәлдә, кулымда даным да, малым да булмады. Ә пистолет… Иң яхшы пистолет ул – мәхәббәт. Атып тидерә алсаң – табышыңа, тидерә алмасаң, шартлау тавышына сөенеп яшисең.

Адәм баласы һәрвакыт шатлыкка мохтаҗ, ул нәрсәгәдер сөенергә тиеш…

Марат КӘБИРОВ

Исәнмесез! Шумбратада!

МОРДВА

Мордва авылына яшел «аю»лар ни өчен килә? Милли бәйрәмнәрдә ник төшкә кадәр өйдән чыгарга ярамый? Мукшы халкының гореф-гадәтләре, мәдәнияте, туган телгә мөнәсәбәте турында кызыксынып, Тәтеш районының Килдеш һәм Киртәле авылларына юл тоттык. «ВТ» хәбәрчесе аларны борчыган проблемаларны да ачыклады.

КУНАКЧЫЛ АВЫЛ

Тәтеш

Үзгәреш

Тәтеш районында мордвалар район халкының 9,5 процентын тәшкил итә. Әлеге халыкның мукшы, эрзя кебек этнотөркемнәргә бүленүен беләбез. Монда дүрт авылда – мукшылар, Бессоново авылында эрзялар яши. Аларның сөйләм теле дә, яшәү үзенчәлекләре дә берникадәр аерыла.

– Мордва халкының милли киемнәре дә, ризыклары да, үз гореф-гадәтләре дә бар. Аларның, милли көрәше юк, диләр. Көрәше дә бар һәм ул аерыла, – ди Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиуллов. – Күптән түгел Килдеш авылында узган Валда шинясь дип аталган милли бәйрәмнәренә Саранскидан тренер чакырттык. Павел Мигунов «Тюштяның фин-угыр хәрби уеннарын яңарту» дигән мастер-класс күрсәтте. Модваларның утарын ясап куйдык. Милли бәйрәмгә 3,5 мең кеше җыелган иде. Игътибар булгач, халык бик канәгать калды. Милли бәйрәмнәр халыкны үзгәртә. Соңгы вакытта мордвалар милли киемнәренә, җырларына игътибар бирә башлады. Алар да үз мәдәниятен, телләрен сакларга тырыша.

Киртәле авылында мукшыларның милли мәктәбе булдырылган. Рәмис Сафиулловның аны район үзәгенә күчереп, милли мәктәп яки үзәк итү теләге дә бар, әмма авылдагы милли мәктәп бетәр дип борчыла. Шуңа күрә бу эшне башларга ашыкмый.

Тәтеш районының Мордва милли-мәдәни үзәге җитәкчесе Ирина Николаева белдергәнчә, районда 9 ансамбль коллективы бар. Әбиләр дә, балалар да, яшьләр дә мәдәнияткә тартыла. Аларны клуб, мәктәп каршында оештырганнар.

– Бездә усал кешеләр юк, барыбыз да кунакчыл, тырыш. Үзебез өчен генә яшәмибез, башкалар турында да уйлыйбыз. Тәкъдимнәргә дә каршы килүче юк, – ди Ирина Ивановна.

Яшьләр шәһәргә кызыга

Килдеш авыл җирлеге башлыгы Виктор Исаев белдергәнчә, авылда 160ләп йорт бар, 320дән артык кеше пропискада тора. Мәктәп, медпункт, почта, парк, фермасы бар. Ике кибет эшли. Йортлар төзек, юлларына таш җәелгән, әмма кайбер урамнарны төзекләндерергә кирәк әле.

Заманында авыл чана, арба ясаучылары белән дан тоткан. Хәзер мондый һөнәрчеләр юк инде. Башка авыллардан аермалы буларак, атна саен базар оештыралар. Читтән килеп, халыкка төзелеш материаллары, продукция тәкъдим итәләр.

– Эшлим дигән кешегә эш бар. Хуҗалыкка механизаторлар кирәк. Яшьләр Ульяндагы мебель фабрикасына барып эшли, атна ахырында кайталар. Вахта белән эшкә баручылар да бар, – ди Виктор Исаев.

Каенана сүзе – закон

Киленнәр дә ерактан килми хәзер. Әнә Зинаида Клементьева 45 ел элек авылга Чувашиядән килен булып килгән. Буада мал табибына укыган кызны юллама белән күрше авылга эшкә җибәргәннәр. Менә шунда булачак ире белән таныша да инде ул.

– Мукшыча бер кәлимә сүз дә белми идем. Ирем белән рус телендә аралаштык. Каенанам Мария: «Мукшы егетенә кияүгә чыккансың икән, телебезне өйрән!» – диде. Ярты ел эчендә сүзләрне аңлый, тагын ярты елдан сөйләшә үк башладым. Әлбәттә, җиңел булмады. Ярты ел үткәч, каенанам: «Хәзер өйдәге барлык эшләрне дә үзең башкар», – диде. Суын да ташыдым, мичен дә яктым, мал-туарын да карадым. Элеккеге киленнәр сүз тыңлаучан иде. Каенанам белән 11 ел тату яшәдек. Ирем 15 ел элек мәрхүм булды. Кызым Ирина атна саен кунакка кайтып йөри, – ди 65 яшьлек Зинаида ханым.

Яшел «аю»лар ник килә?

Әлеге ике авыл бер-берсенә якын булса да, бәйрәмнәре аерылып тора.

– Троисын бәйрәменең икенче көнендә йортларга яшелдән киенеп, алты «аю» килә. Алар өсләренә өрәңге ботаклары ябалар. Бу көнне тәрәзә кашагаларын, ишегалдындагы коеларны да яшеллек белән бизиләр. Аю ул – безнең талисман. Яшел «аю»лар, һәр йорт янында туктап, маллары артсын, гаиләдә сәламәтлек булсын, дип теләк тели, – дип сөйләде безгә Килдеш авылы халкы.

Бу авылда Кач ману бәйрәме, ягъни 18 гыйнвар төнендә сәгать 12дә Кирәмәт чишмәсенә барып юыну гадәте дә бар. Сафландырылган суны өйләренә алып кайталар.

«Валда шинясь» сүзе «кояшлы көн» дигәнне аңлата. Быел бәйрәм уза торган мәйданчыкка аю һәм циферблат рәвешендәге кояш сәгате куйганнар. Монда мордва халкының баһадиры Тюштя сыны тора. Мордва утарында агач йорт салганнар, анда музей оештырырга җыеналар.

Гадәтләр онытыла бара...

Хәзерге авыл бөтенләй башкача яши, ди мукшылар. Урамда табын корып, җырлашып утырулар да үткәндә калган. Балага исем кушу, туй һәм башка йолалар да үзгәреш кичергән. Тик мукшылар мәрхүм әби-бабаларын онытмый, елга 4 тапкыр зиратка барып, рухларын искә алалар.

68 яшьлек Клавдия Ишелева белән бергәләп йолаларны барладык. Ул 45 ел элек Киртәле авылыннан килен булып килгән.

– Элек әби борчактан пирог пешерә иде. Бар, такмакла дип, мине ишек артына чыгарып җибәрә иде. Мин шунда җырлый идем, – дип искә төшерә ул бала чагын. – 7 гыйнварда Раштуада иртәнге сәгать 4тә өйдән-өйгә йөреп, акча җыя, хуҗаларга теләк тели идек.

Бу йолага бәйле ырым-шырымнар да бар. Ишекләр гел ачык булырга тиеш икән. Аннан ир баланың беренче керүе яхшыга юралган. Янәсе, шул йортта яшәүчеләргә байлык, иминлек керсен өчен бу. Иске Яңа елда, ягъни 14 гыйнварда төшкә кадәр берәүгә дә урамда йөрергә ярамый. Имеш, әгәр йортка берәр кеше керсә, аның хуҗасы яки мал-туары чирли. Дөрес, бу ышануларга яшьләр хәзер әллә ни игътибар бирми икән.

Туйларның ничек узуы белән дә кызыксындык. Беренче көнне егет ягы кызның кулын сорарга килә. Шәм яндырып, дога укыйлар. Кодагыйлар арасында дуслык нык булсын өчен, уң кулларына сөлге тотып күрешәләр. Өстәлгә акча салу өчен тәлинкә куела. Безнеңчә, мәһәр инде бу. Икенче очрашу: ярәшкән вакытта һәр йорттан бер кеше килә, алар туйда да катнашырга тиеш. Туй көнне исә туганнар, күршеләр җыелыша. Алар ботка, ипи алып килә. Хәзер андый нәрсә юк икән. Кәләш почмакта башын аска иеп утыра, битенә япкан шәлне ачарга ярамый. Кызны ике яктан абыйлары алып чыгып, аны атка, машинага утыртып алып киткән. Кыскасы, элек кияүгә шушы тәртиптә биргәннәр.

Сүзлек

Исәнмесез – **Шумбратада**
Сау булыгыз – **Няемозонк**
Рәхим итегез – **Сада пара мяльса**
Бәхетле булыгыз – **Уледа павазуфт**
Кунакка килегез – **Сада инжикс**
Авыл – **Веле**
Милләт – **Нация**
Рәхмәт – **Сюкпря**
Гаилә – **Семика**
Татулык – **Ладяма**
Дуслык – **Ялгаксши**
Мәхәббәт – **Кельгома**

Кемне яраталар, шуңа чыгалар

Киртәле авылында да йөздән артык йорт исәпләнә. Авылның кибете, клуб, мәктәбе, китапханәсе, фермасы да бар. Юлларына таш түшәлгән. Безне мәдәният йортында авылның актив әбиләре каршы алды. Алардан башка бер бәйрәм дә узмый икән.

Татьяна Титовага – 67. Ул 16 яшьтән сыер сауган. «Фермада да эшләдек, чөгендерен дә эшкәрттек, печәнен дә чаптык. Тормыш җиңел хәзер», – ди ул.

Татьяна Зермянкина әйтүенчә, элек мукшыга гына өйләнсә яки кияүгә чыксалар, хәзер андый таләпләр юк. Кемне яраталар, шуңа чыгалар. Катнаш никахлар да бар. Өлкәннәр өйдә туган телдә аралашса, балалар русчага каера.

Әбиләр хәзерге мул тормыш өчен сөенеп бетә алмый. «Хәзер үзебез дә ялкауландык. Элек чигә, бәйли, тегә идек. Ипи дә пешермибез бит, пирогларны да кибеттән генә сатып алабыз. Әбиләребез милли киемнән йөрсә, алъяпкыч бәйләсә, без андый түгел. Аны бәйрәмнәрдә генә киябез, – дип елмая замана әбиләре. – Өйдә барлык мөмкинлекләр тудырылган. Пенсияне вакытында бирәләр. Безне рәхәттә яшәткән өчен ике Президентка да рәхмәт».

Тәмле булсын!

Крахмалонь шянявкст (Крахмал коймагы)

Моның өчен 700 грамм сөт, 2–3 данә йомырка, 600 грамм крахмал, чама белән тоз, сода кирәк. Шулардан камыр изәбез. Аннан табаны майлап, коймак пешерәбез. Әзер коймакны шакмаклар рәвешендә кисеп, чуенга саласы. Шуннан соң сөт агызып, бераз атланмай кушасы. Мичтә яки талгын гына утта кабарганчы тотарга кирәк. Коймаклар әзер, табынга куйсаң да була.

Тел – мәдәният аша

Әлеге авылларда яшәүчеләр барысы да туган телен белә, тик яшьләр урамда русча сөйләшергә тырыша икән. Бу әле тел гаиләдә сакланмый дигән сүз түгел. Мәктәптә исә фанат укытучылар мукшы телен онытырга ирек бирми. Тик дәрес буларак, Килдеш мәктәбендә ул укытылмый икән.

Килдеш урта мәктәбенә дүрт авылдан килеп белем алалар. Алар арасында татар, рус, чуаш, мордва балалары да укый. Узган уку елында 54 бала белем алган. Башлангычта 12 бала укыган, монда ике сыйныфны бергә кушып укыталар. Быел 1 нче сыйныфка 3 укучы барачак. Людмила Долгова – башлангыч сыйныф укытучысы, «Минем кече Ватаным» берләшмәсе җитәкчесе.

– Бездә мукшы теле укытылмый. Элегрәк дәрестән тыш атнага ике сәгать керә иде, хәзер юк. Хет түгәрәктә булса да сөйләм теленә өйрәтәсе килә. Әмма, кызганыч, укытучы юк. Балалар белән мукшы телендә сөйләшергә тырышабыз. Бергәләп авылның такмакларын җыйдык. Төрле бәйгеләрдә катнашабыз. Авылда мәдәният күтәрелә бара, – ди укытучы.

Киртәле мәктәбендә мукшы теле укытыла. Анда укучыларның туган тел бәйгеләрендә җиңүләрен беләбез. Монда нибары 19 бала белем ала. Укучылар саны урта мәктәп өчен бик аз булса да, милли мәктәпне саклыйлар. Галина Абраконова 21 ел мукшы телен укыта.

– Туган тел атнага 3 сәгать керә, шуның икесе – мукшы теле һәм берсе – әдәбият. Бездә этиәниләрнең барысы да туган телне саклый. Каршы килүче берәү дә юк. Быел 1 нче сыйныфка 1 бала барачак. Мордовиядән дәреслекләр җибәреп торалар. Дәрестә милли мәдәниятне, уеннарны, костюмнарны да өйрәнәбез. Әдәбиятны өйрәнү өчен бер генә сәгать җитми анысы. Тагын арттырсалар да ярый. Шул ук вакытта безгә туган телләрне өйрәнү мөмкинлеге тудырган өчен рәхмәт әйтәсе килә. Хәзерге вакытта бер егетебез вузда милли юнәлеш буенча укый, – ди Галина Абраконова.

ОНЫТЫЛГАН КӨРӘШ

Мордва халкының милли бәйрәме булдырылса, бил алышу гадәткә керәчәк һәм аның турында башкалар да беләчәк. Саранск шәһәрендә яшәүче, милли көрәш, традицион фин-угыр уеннары «Тюштянь налксемат»ны («Игрища Тюшти») яңарту проекты җитәкчесе Павел Мигунов халык уеннарына игътибарны күбрәк бирергә кирәк дип саный.

Павел Мигунов күптән түгел Тәтеш районында узган Валда шинясь бәйрәмендә халык уеннары буенча мастер-класс та күрсәткән. Тренер Мордовиядә балаларга көрәш серләрен өйрәтә. Без аның белән әлеге юнәлешне үстерү һәм саклау турында сөйләштек.

– Бездә милли көрәш онытылган. Әгәр татарларның Сабан туе кебек милли бәйрәм уздырылса, һичшиксез, танылган булыр иде. Хәзер шуны үстерү буенча эшлибез. Мордва ярышлары турында күбрәк сөйләргә һәм аны барлык төбәк чараларына кертергә кирәк. Мордва халкы элек бүрәнә күтәргән, йодрык сугышлары оештырган, уктан аткан, ераклыкка агач шар ыргыткан. Болар бит – безнең мәдәниятнең бер өлеше. Милли бәйрәмдә иң мөһиме – катнашу. Кемнең отачагы мөһим түгел. Халык бәйрәмнән ләззәт алырга тиеш, – ди Павел Мигунов.

2000 елда Павел Мигунов көрәш ярышларында «Торама» фольклор ансамблен оештыручы Владимир Ромашкин белән очрашкан. Аның белән милли спорт ярышларын торгызу турында сөйләшкән алар. Шуннан соң бергәләп милли уеннарны торгызу буенча иҗат коллективы оештырганнар.

– Тюштя – мордва халкына юл күрсәтүче герой. Ул халыкны һөнәрчелеккә өйрәткән, дәүләтен барлыкка китергән. Мордва җиренә дошманнар килгәндә, гаскәрләрен җыеп, сугыш сәнгатенә өйрәткән. Менә шуның өчен проектка шундый исем бирдек, – ди әңгәмәдәшем.

Мигунов үз халкының улларын көчле рухлы, мәдәниятен белгән зыялы итеп күз алдына китерә. Аның фикеренчә, спорт түгәрәкләренә милли-төбәк компонентын кертү, милли традицион уеннар буенча ярышлар, даими эшләүче этнолагерь оештыру мөһим. Моның өчен ниндидер зур чыгымнар кирәкми. Мәйданчыклар булса, үзе ул теләсә кайсы урынга барып, көрәш үзенчәлекләрен күрсәтергә әзер.

Тренер «этно-кудо» музей-йорты тирәсендә чаралар еш уздыра икән. «Балаларга ярышлар бик ошый. Алар капчык белән сугыша, аркан тартыша, аркан аша сикерә. Кызыксынуларын күргәч, күзгә яшьләр килә хәтта», – ди ул.

Сәхифәне Сәрия МИФТАХОВА әзерләде.
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 303

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+